ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 июль 2024 ел № 4309

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә тормышка ашырыла торган һәм (яки) тормышка ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларын карап тикшерү һәм аларга булышлык итү турында

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Законы нигезендә, инвестиция активлыгын арттыру һәм инвестиция эшчәнлеген үстерү өчен уңай шартлар тудыру, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә тормышка ашырыла торган (тормышка ашыру планлаштырыла торган) инвестиция проектлары буенча мәгълүматларны исәпкә алуны системага салу максатларында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Раславга:
1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә тормышка ашырыла торган һәм (яки) тормышка ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларын карап тикшерү һәм аларга булышлык итү регламентын, 1 нче кушымтада каралганча;
2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә инвестиция проектларын карап тикшерү буенча комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 5 июлендәге
4309 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә тормышка ашырыла торган һәм (яки)
тормышка ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларын
карап тикшерү һәм аларга булышлык итү
регламенты

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә тормышка ашырыла торган һәм (яки) тормышка ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларын карап тикшерү һәм аларга булышлык итү регламенты (алга таба – Регламент) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә тормышка ашырыла торган һәм (яки) тормышка ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларын карап тикшерү һәм аларга оештыру ягыннан булышлык итү тәртибен билгели.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруны планлаштыручы һәм (яки) тормышка ашыручы инвесторларга оештыру ягыннан булышлык итүне гамәлгә ашыра торган вәкаләтле структур бүлекчә булып Башкарма комитетның алгарышлы үсеш территориясен үстерү бүлеге (алга таба – Вәкаләтле сруктур бүлекчә) тора.

3. Әлеге Регламент максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

инвестиция проекты – капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруның икътисадый максатчанлыгын, күләмен һәм срокларын нигезләү, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә инвестицияләрне гамәлгә ашыру буенча практик гамәлләр тасвирламасы;

инвестор – инвестицияләр рәвешендә үзенең, заем яки җәлеп ителгән акчаларны кертүне гамәлгә ашыра торган һәм алардан максатчан файдалануны тәэмин итә торган инвестиция эшчәнлеге субъекты;

инвестиция проекты инициаторы (алга таба – инициатор) – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә тормышка ашыру өчен инвестиция проектын тәкъдим итүче инвестор;

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә инвестиция проектларын карап тикшерү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыру мөмкинлеген карап тикшерә торган коллегиаль киңәшмә органы;

инвестиция мәйданчыгы – максатчан үзләштерү һәм перспективалы үсеш өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан азат булган, локальләштерелгән территория;

инвестиция проекты кураторы – тармакка мөнәсәбәтле инвестиция проекты нигезендә, инвестиция проектына булышлык итү өчен җаваплы Башкарма комитет вазыйфаи заты.

Регламентта кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

4. Вәкаләтле структур бүлекчә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыру максатларында:

1) Комиссия тарафыннан проектларның карап тикшерелүен дә кертеп, инвестиция проектларына булышлык итүне оештыруны тәэмин итә;

2) үз компентенциясе чикләрендә инвестиция проектлары инициаторларына консультация, мәгълүмати һәм хокукый ярдәм күрсәтә;

3) инвестиция проектларын тормышка ашыру кысаларында киңәшмәләр оештыруда һәм үткәрүдә, шул исәптән гамәлдәге законнар нигезендә, Башкарма комитетның тармак (функциональ) бүлекчәләре, федераль һәм республика хакимият органнарының территориаль органнары, инвестиция эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү буенча дәүләтнеке булмаган институтлар белән үзара эшчәнлек мәсьәләләре буенча ярдәм күрсәтә.

## 2 бүлек. Инвестиция проектларын карап тикшерү тәртибе

5. Инвестиция проектын карап тикшерү өчен нигез булып, инициатор таафыннан Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә инвестиция проектын тормышка ашыру нияте турында мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) җибәрү тора.

6. Инициатор тарафыннан мөрәҗәгать түбәндәге ысуллар белән җибәрелергә мөмкин:

1) кәгазь йөрткечтә – түбәндәге адрес буенча: 423805, Яр Чаллы, Хәсән Туфан проспекты, 23;

2) электрон рәвештә – мөрәҗәгатьне электрон адреска җибәрү юлы белән: kancel.chelny@tatar.ru.

7. Мөрәҗәгать, Регламентка 1 нче кушымтада каралганча инвестиция проекты паспортын һәм проект презентациясен теркәп, ирекле рәвештә языла.

8. Документлар чит телдә тапшырылган очракта, инвестор (инициатор) тарафыннан расланган, рус теленә тәрҗемә теркәлергә тиеш.

9. Тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен инициатор җаваплы.

10. Инвестор (инициатор), Регламентның 7 пунктында күрсәтелгән документлар комплектын әзерләү буенча аңа методик (консультация) ярдәм күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт ярдәме инструментларыннан файдалану, Регламент нигезләмәләрен аңлату буенча Вәкаләтле структур бүлекчәгә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

11. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе, инвесторның (инициаторның) мөрәҗәгатен теркәгәннән соң, алынган материалларны карап тикшерү өчен Вәкаләтле структур бүлекчәгә һәм Башкарма комитетның тармак бүлекчәләренә җибәрә.

12. Башкарма комитетның структур бүлекчәләре, мөрәҗәгатьне теркәгән көннән башлап 20 календарь көн эчендә, аңа анализ ясыйлар һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә инвестиция проектын тормышка ашыру мөмкинлекләре һәм шартлары турында нигезле фикерне (тиешле тармак өчен инвестиция проектына ихтыяҗны һәм аның әһәмиятен, аны тормышка ашыру өчен мәйданчыклар һәм ресурслар булуны күрсәтеп) Вәкаләтле структур бүлекчәгә җибәрәләр.

13. Вәкаләтле структур бүлекчә Комиссия өчен гомумиләштерелгән беренчел бәяләмәне әзерли.

## 3 бүлек. Комиссия тарафыннан инвестиция проектларын карап тикшерү тәртибе

14. Комиссия составы Башкарма комитет карары белән раслана.

15. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм Комиссия әгъзаларыннан тора.

16 Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырышны чакыру һәм үткәрү срогы турында карар кабул итә.

17. Комиссия рәисе урынбасары комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм, рәис йөкләмәсе буенча, ул булмаганда Комиссия утырышларында рәислек итә.

18. Комиссия секретаре Комиссия утырышларына әзерлекне координацияләүне гамәлгә ашыра, утырышларга материаллар әзерли. Утырышларны мәгълүмати-аналитик һәм оештыру-техник тәэмин итүне, шулай ук аның утырышларында кабул ителә торган карарларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

19. Комиссия утырышында аның исемлек составының кимендә яртысы катнашса, ул тулы хокуклы була.

20. Комиссия утырышы заявкалар җыелган саен, әмма карап тикшерү өчен инвестиция проектлары булганда, аена кимендә 1 тапкыр үткәрелә.

21. Комиссия утырышын үткәрү урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, утырыш үткәрелгәнче 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле структур бүлекчә тарафыннан инициатор адресына җибәрелә.

22. Комиссия утырышка тапшырылган материалларны карап тикшерә һәм йомгак ясый.

23. Комиссия утырышында инвестор (инициатор) ачык чыгыш ясау формасында инвестиция проектын презентацияли .

24. Инвестиция проектын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, Комиссия ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш нигезендә, аны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә тормышка ашыруның максатчан булуы яки максатчан булмавы һәм инвестиция проекты инициаторына ярдәм күрсәтү зарурлыгы (мөмкинлеге) турында карар чыгара, алга таба булышлык итү өчен проект кураторын билгели.

25. Әгәр инвестиция проектларын тормышка ашыруның максатчанлыгы яки максатчан булмавы турында карар кабул иткәндә «риза» һәм «каршы» тавышларының саны тигез булса, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була. Комиссия рәисе булмаганда, Комиссия рәисе урынбасарының тавышы хәлиткеч булып тора.

26. Комиссия карарлары комиссия секретаре алып бара торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмә, комиссия утырышы үткәрелгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн срокта, Комиссия рәисе тарафыннан раслана. Беркетмә үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, Комиссиянең катнашучы әгъзалары, инвестиция проектларын карап тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүматтан гыйбарәт. Комиссия утырышы үткәрелгән көннән башлап 5 эш көне эчендә, Вәкаләтле структур бүлекчә тарафыннан проект инициаторына беркетмәдән өземтә җибәрелә.

27. Инициатор Комиссиянең гамәлләренә (гамәл кылмавына) законда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

## 4 бүлек. Йомгаклау бәяләмәләре

28. Инвестиция проектының кураторы инвестиция проектына оештыру ягыннан булышлык итә:

1) инвестиция проектын тормышка ашыру өчен җир участогы сайлап алуда һәм инвестиция проектын инвестиция мәйданчыгында урнаштыруда;

2) төзелешкә проект документларын килештерүдә, объектны төзүгә рөхсәт алуда һәм аны файдалануга тапшыруда;

3) инвестиция проектын тормышка ашыру өчен кирәкле башка рөхсәт бирү документларын рәсмиләштерүдә;

4) Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы белән, шулай ук ресурслар белән тәэмин итә торган оешмалар белән үзара эшчәнлектә ярдәм күрсәтү.

29. Инвестиция проектын тормышка ашырганда Башкарма комитет компетенциясенә карамаган проблемалы мәсьәләләр барлыкка килгән очракта, инвестиция проектының кураторы тарафыннан тиешле федераль хакимият органнарына һәм башка оешмаларга запрос җибәрелә.

30. Инвесторларга дәүләт, муниципаль ярдәм күрсәтү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында, шулай ук муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

31. Вәкаләтле структур бүлекчә, Регламентка 2 нче кушымтада каралганча, тормышка ашырыла торган инвестиция проектлары реестрын алып бара. Тормышка ашырыла торган инвестиция проектлары реестрын актуальләштерү даими нигездә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яки) гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларын карап тикшерү һәм аларга булышлык итү регламентына
1 нче кушымта

Инвестиция проекты паспорты

| | | |
|---|---|---|
| ________________________________________ инвестиция проектының (ИП) исеме | | |
| 1. | ОКВЭД нигезендә ИП буенча икътисадый эшчәнлек төре | |
| 2. | ИПны тормышка ашыру урыны (ТР районы, торак пункт) | |
| 3. | ИПның характеры («нуль»дән төзелеш, реконструкция, модернизация, гамәлдәге производствода яңа продукция чыгару, гамәлдәге производствоны киңәйтү, башкалар) | |
| 4. | ИПның максаты һәм, табигый һәм акчалата чагылышта еллык проект куәтен күрсәтеп, аның асылын кыскача тасвирлау | |
| 5. | ИПның Яр Чаллы шәһәренең социаль-икътисадый үсеш бурычларына, аларны раслау буенча тиешле норматив хокукый актларны күрсәтеп, үсешнең тармак стратегияләре (программалар, концепцияләр) өстенлекләренә туры килүен нигезләү | |
| 6. | ИПны тормышка ашыру сроклары (төп капиталга инвестицияләр кертү чоры), шул исәптән аның төп этаплары: | |
| 6.1. | инвестиция алды тикшеренүләре, проект документларын/бизнес-план эшләү | |
| 6.2. | килештерү һәм рөхсәт бирү документларын алу | |
| 6.3. | төзелеш | |
| 6.4. | җиһазлар сатып алу һәм кайтару | |

<table>
<tr><td>6.5.</td><td>проектны эшләтеп җибәрү (файдалануга тапшыру)</td><td></td></tr>
<tr><td>6.6.</td><td>проект куәтенә чыгу</td><td></td></tr>
<tr><td>7.</td><td>ИПның эшләнү дәрәҗәсе (ИПны тормышка ашыру кирәклеге турында карар кабул итү датасы һәм дәрәҗәсе, проект документларының әзерлек дәрәҗәсе (дәүләт экспертизасы бәяләмәләре булу), ИПны тормышка ашыру буенча элек үткәрелгән һәм хәзерге вакытта гамәлгә ашырыла торган чаралар, ИПны тормышка ашыру кысаларында күрсәтелгән дәүләт ярдәме формалары)</td><td></td></tr>
<tr><td>8.</td><td>ИПның гомуми бәясе (ӨКС белән), млн сум</td><td></td></tr>
<tr><td>9.</td><td>ИПны тормышка ашыру еллары буенча инвестицияләр кертү, млн сум</td><td><table><tr><td>20__</td><td>20__</td><td>...</td><td>20__ n</td></tr><tr><td></td><td></td><td></td><td></td></tr></table></td></tr>
<tr><td>10.</td><td colspan="2">ИПны финанслау чыганаклары, млн сум:</td></tr>
<tr><td>10.1</td><td>үз акчалары (табыш, амортизация)</td><td><table><tr><td rowspan="2">Барлыгы</td><td colspan="4">шул исәптән еллар буенча</td></tr><tr><td>20__</td><td>20__</td><td>...</td><td>20__ n</td></tr><tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr></table></td></tr>
<tr><td>10.2.</td><td>җәлеп ителә торган акчалар, шул исәптән:</td><td><table><tr><td rowspan="2">Барлыгы</td><td colspan="4">шул исәптән еллар буенча</td></tr><tr><td>20__</td><td>20__</td><td>...</td><td>20__ n</td></tr><tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr></table></td></tr>
<tr><td>10.2.1.</td><td>банклар кредитлары</td><td><table><tr><td rowspan="2">Барлыгы</td><td colspan="4">шул исәптән еллар буенча</td></tr><tr><td>20__</td><td>20__</td><td>...</td><td>20__ n</td></tr><tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr></table></td></tr>
<tr><td>10.2.2.</td><td>Россия Федерациясе бюджеты акчалары</td><td><table><tr><td rowspan="2">Барлыгы</td><td colspan="4">шул исәптән еллар буенча</td></tr><tr><td>20__</td><td>20__</td><td>...</td><td>20__ n</td></tr><tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr></table></td></tr>
<tr><td>10.2.3.</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчалары</td><td><table><tr><td rowspan="2">Барлыгы</td><td colspan="4">шул исәптән еллар буенча</td></tr><tr><td>20__</td><td>20__</td><td>...</td><td>20__ n</td></tr><tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr></table></td></tr>
<tr><td>10.3.</td><td>чит ил инвестицияләре, шул исәптән:</td><td><table><tr><td rowspan="2">Барлыгы</td><td colspan="4">шул исәптән еллар буенча</td></tr><tr><td>20__</td><td>20__</td><td>...</td><td>20__ n</td></tr><tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr></table></td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10.3.1. | турыдан-туры чит ил инвестицияләре | Барлыгы | шул исәптән еллар буенча<br>20__ ; 20__ ; ... ; 20__ n |
| 11. | ИПны финанслауның тәэмин ителеш дәрәҗәсе (документаль расланган финанслау чыганаклары), ИПның гомуми бәясеннән % | | |
| 12. | Инвестиция чыгымнары структурасы һәм аларны үзләштерү дәрәҗәсе: | Бәясе, млн сум | Планлаштырылган күләмнән кертелгән акчалар өлеше, % |
| 12.1. | капиталь чыгымнар, шул исәптән: | | |
| 12.1.1. | проектлау | | |
| 12.1.2. | җир сатып алу | | |
| 12.1.3. | төп чараларны сатып алу | | |
| 12.1.4. | төзелеш-монтаж эшләре | | |
| 12.1.5. | җиһаз сатып алу | | |
| 12.1.6. | инвестиция фазасындагы башка чыгымнар | | |
| 12.2. | әйләнештәге капиталга инвестицияләр | | |
| 13. | ИПны тормышка ашырганда булган проблемалар (ресурслар җитмәү, җир участогын бүлеп алу/сатып алу, финанслау җитмәү, инфраструктура булмау/җитмәү (тышкы инфраструктура объектларын да кертеп), сату базары булмау, оештыру һәм башкалар) һәм аларны хәл итү буенча тәкъдимнәр | | |
| 14. | Потенциаль инвесторлар һәм партнерлар белән хезмәттәшлекнең мөмкин булган формалары (технологияләр трансферы, инжиниринг; җиһаз белән тәэмин итүчеләрне эзләү; сату базарларын киңәйтү; өлешләп финанслау; бурычлы финанслау, гарантия (поручительлек) бирү һ.б.) | | |
| 15. | Кредит акчаларын (банк гарантиясе, поручительлек, залог, башкалар) җәлеп иткән очракта, ИП буенча тәэмин ителеш булу | | |
| 16. | Дәүләт һәм үсеш институтлары ягыннан ярдәм күрсәтүнең күздә | | |

| | | |
|---|---|---|
| | тотыла торган формасы | |
| 17. | ИПның финанс-икътисадый, бюджет һәм социаль нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең зурлыклары: | |
| 17.1. | чиста дисконтланган керем (NPV), млн сум | |
| 17.2. | чыгымнар каплануының гади срогы, ел | |
| 17.3. | чыгымнар каплануының дисконтланган срогы, ел | |
| 17.4. | керемле булуның эчке нормасы (IRR), % | |
| 17.5. | проект куәтенә чыкканда бер ел эчендә ИП генерирлаштыра торган өстәмә кыйммәт, млн сум (салым салуга кадәр табыш, бурыч йөкләмәләре һәм амортизация чигерүләре буенча процентлар түләү + хезмәткәрләрнең суммар хезмәт хакы + аренда түләве) | |
| 17.6. | проект куәтенә чыкканда Яр Чаллы шәһәренең консолидацияләнгән бюджетына салым кертемнәре күләме, млн сум | |
| 17.7. | ИП кысаларында булдырыла торган эш урыннары саны, берәмлек | Барлыгы \| шул исәптән еллар буенча:<br>20__ \| 20__ \| ... \| 20__ n |
| 18. | ИП оешма-инвесторы турында мәгълүмат: | |
| 18.1. | Оешманың исеме | |
| 18.2. | Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасының исеме | |
| 18.3. | оешманың фактик адресы | |
| 18.4. | элемтә телефоны номеры | |
| 18.5. | электрон почта адресы | |
| 19. | ИП буенча элемтәдәге затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы, телефоны, электрон почта адресы | |
| 20. | Җир участогы (район, урнашу урыны, мәйданы (кв.м). | |
| 21. | Инфраструктура/ресурслар төрләренә һәм куәтләргә ихтыяҗ: | |
| 21.1. | электр белән тәэмин итү (МВт) һәм ышанычлылык категориясе | |
| 21.2. | газ белән тәэмин итү | |
| 21.2.1. | (нм$^3$/сәг) | |
| 21.2.2. | (нм$^3$/ел) | |
| 21.2.3. | (басым) | |
| 21.3. | су белән тәэмин итү: | |
| 21.3.1. | гомуми (м$^3$/тәүлек) | |

| | | |
|---|---|---|
| 21.3.2. | эчә торган ($м^3$/тәүлек) | |
| 21.3.3. | техник ($м^3$/тәүлек) | |
| 21.4. | Хуҗалык-көнкүреш агынты суларын бүлү ($м^3$/тәүлек) | |
| 22. | Паспортны тутыру датасы | |
| 23. | Проект инициаторы (инвестор) компаниясенең исеме/Җитәкченең Ф.И.А.и. | |
| 24. | Җаваплы затның Ф.И.А.и. | |
| | Комиссия утырышын үткәрү датасы һәм вакыты турында хәбәр итү өчен почта адресы һәм электрон адрес | |

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә тормышка ашырыла торган һәм (яки) тормышка ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларын карап тикшерү һәм аларга булышлык итү регламентына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә тормышка ашырыла торган һәм (яки) тормышка ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектлары
РЕЕСТРЫ

| № т/б | Инвестиция проекты инициаторы | Проектның исеме һәм кыскача тасвирламасы | Проектны тормышка ашыру урынының адресы | Инвестицияләр күләме, млн. сум | Проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә эш урыннары саны, берәмлек | Проектның кураторы | Проектны тормышка ашыру стадиясе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Башкарма комитетның
2024 елның 5 июлендәге
4309 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә инвестиция проектларын карап тикшерү буенча комиссия составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Салахов Фәрид Шавкат улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Кропотова Наталия Анатольевна | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 3. | Бикташева Алия Шамил кызы | комиссия секретаре, Башкарма комитетның алгарышлы үсеш территориясен үстерү бүлеге башлыгы |
| комиссия әгъзалары: | | |
| 4. | Видинеева Ләйсән Әлфит кызы | Башкарма комитетның яшьләр бедән эшләү идарәсе башлыгы |
| 5. | Вилданов Руслан Флер улы | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 6. | Гыйззәтуллин Ленар Рәис улы | Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы |
| 7. | Гыйләҗева Гүзәл Вәлиәхмәт кызы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы |
| 8. | Дерлюкова Елена Владимировна | Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы |
| 9. | Зәйнетдинов Гадел Марсель улы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы урынбасары, эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү бүлеге башлыгы |
| 10. | Зуев Илья Сергеевич | Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 11. | Кәрамиев Румил Рәүф улы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 12. | Лашин Алексей Николаевич | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы |

| | | |
|---|---|---|
| 13. | Мулюкова Светлана Рафаиль кызы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы |
| 14. | Насрединов Роман Мансур улы | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе башлыгы |
| 15. | Нигъмәтҗанова Олеся Игоревна | Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының инвестицион проектларны алып бару һәм ярдәм итү бүлеге башлыгы |
| 16. | Харисов Винер Хәмит улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 17. | Хуҗин Рөстәм Нияз улы | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы |
| 18. | Фәттахов Мансур Әдип улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева